# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авылы Иске Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Иске Имән торак пунктнының авыл эчендәге Мулланур Вахитов, Нәҗип Вахитов урамы юлларын ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау, сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).
- Иске Имән торак пункты урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урамнарны яктырту);
- Иске Имән торак пунктының Каратал урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру ( килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Имән торак пункты юлларын грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Иске Имән торак пунктында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);
- Беларусь-МТЗ 320.4-Ч махсус техникасын тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыю урыннарын җыештыру;

- Иске Имән торак пунктында Бөек Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова